РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

08.11.2022

№ 1130-п

«2021-2025 елларга Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районының муниципаль
мөлкәте белән идарә итү» муниципаль
программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. «2021 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль мөлкәте белән идарә итү» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 21 октябрендәге 1407-п номерлы карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль мөлкәте белән идарә итү» муниципаль программасына (алга таба - Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программаның паспорты таблицасында «Программаны финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре | 2021 - 2025 елларда Программаны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына финанслауның гомуми күләме 14 715,299 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2021 ел - 3 056,350 мең сум;<br>2022 ел - 3 965,379 мең сум;<br>2023 ел - 2 535,015 мең сум;<br>2024 ел - 2 535,015 мең сум;<br>2025 ел - 2 623,540 мең сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына)Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштереләчәк. |

»;

1.2. «Программаны ресурслар белән тәэмин итү» 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«3. Программаны ресурслар белән тәэмин итү**

2021 - 2025 елларда Программаны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына финанслауның гомуми күләме 14 715,299 мең сум тәшкил итә,

шул исәптән:

2021 ел - 3 056,350 мең сум;

2022 ел - 3 965,379 мең сум;

2023 ел - 2 535,015 мең сум;

2024 ел - 2 535,015 мең сум;

2025 ел - 2 623,540 мең сум.

Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына)Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштерeләчәк.

1.3. Программаның 1 нче кушымтасын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе А.М. Галиуллинга йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Ишниязов

Саба муниципаль районы Башкарма
комитеты карарына 1  кушымта

«2021-2025 елларга Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районының муниципаль
мөлкәте белән идарә итү» муниципаль
программасына 1 кушымта

**"2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының**
**униципаль мөлкәте белән идарә итү" муниципаль программасы**

| Программаның исеме | Башкаручы | Финанслау чыганагы | Программаны гамәлгә ашыруга акча күләме, мең сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | БАРЛЫГЫ | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| “2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль мөлкәте белән идарә итү” | Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы | Җирле бюджет | 14 715,299 | 3 056,350 | 3 965,379 | 2 535,015 | 2 535,015 | 2 623,540 |